# ХАЛЫК АВАЗЫ



3 март көнне сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист – **Сәрия МИФТАХОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.



Илдар Мөхәммәтҗанов

## 50 ел бергә. Нигә безгә бүләк юк?

Казан шәһәренең башкарма комитеты 50, 60, 70 ел бергә яшәгән гаиләләргә акча бирә. Ник авыл җирендә яшәүчеләргә андый бүләк юк? Гыйнвар аенда бергә яши башлавыбызга 50 ел булды, 5 бала үстердек. Үземә быел 75 яшь тула. Шөкер, мохтаҗлык юк, бөтен нәрсәбез дә бар. Тик күңел хөрмәт көтә.

МИФТАХЕТДИНОВА Зәмзәмия.
Аксубай районы Иске Кыязлы авылы

**Аксубай районының ЗАГС идарәсе:**
– Һәр муниципалитетның башкарма комитеты түләүләрне үзе билгели. Безнең районда андый мөмкинлек юк. Ел саен юбилярларны хөрмәтләү кысасында Рәхмәт хатлары тапшырабыз. Аларны авыл җирлеге советы гаризасы белән яисә туганнары теләге буенча котлыйбыз.

## Чит илдә укып буламы?

Кызым 10 нчы сыйныфта укый. Инглиз телен шомарту өчен, җәйге каникулда берәр программа буенча чит илдә укып булмыймы? Шунда яшәп, аралашып, ил культурасын өйрәнеп кайтыр иде.

РӘЗИНӘ. Казан

**Мәгариф һәм фән министрлыгы матбугат үзәге:**
– Министрлык тарафыннан мәктәп укучылары өчен андый программалар каралмаган. Студентлар, Хөкүмәт грантын отып, чит илдәге уку йортларына керә ала. Татарстан яшьләренә чит илгә китеп белем алырга «Алгарыш» гранты ярдәмгә килә. Әлеге программа республикабызда 2006 елдан бирле эшли. Студентлар үзләре белем ала торган уку йорты һәм аның партнер университетлары арасындагы студентлар алмашы программасы буенча да чит илгә китеп укып кайта алалар.

## Стаж сатып алып буламы?

Сезнең газетада, пенсиягә иртәрәк чыгу өчен, стаж сатып алу турында укыдым. Иремә быел 60 яшь тула. Колхозчы ул, 39 елдан артык стажы бар. 1961 елда туганнарның армиядә хезмәт иткән вакыты стажга керми дип тә ишеттем. Без стаж сатып ала алабызмы?

ӘЛФИЯ. Тәтеш районы

**Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге:**
– Лаеклы ялга чыгу өчен, кешенең җитәрлек иминият стажы булырга тиеш. 2023 елда картлык буенча иминият пенсиясен алу өчен минималь стаж 14 ел тәшкил итә. Җитеп бетмәгән стажны сатып та алып була. Моның өчен Пенсия фондына гариза язып, тиешле акчаны түләргә кирәк. Сатып алынган стаж гариза язган көннән исәпләнәчәк. Моннан тыш, авыл җирендә яшәүче, эшләми торган һәм 30 елдан артык авыл стажы булган кешеләр пенсиясенә өстәмә түләүләр каралган. Узган елның 1 гыйнварыннан өстәмә түләүне авылдан күченгәннән соң да алырга мөмкин. Авыл пенсионерларына өстәмә түләү хокукы бирә торган стажны санаганда, колхоз, совхоз һәм башка авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә һәм оешмаларындагы эшләр исәпкә алына. Боларга терлекчелек, үсемлекчелек һәм балыкчылык керә.

Ләйсән САФИНА әзерләде

# Күрше хакы

**9 миллион сум! Татарстанда милек хуҗаларының җылылык өчен дөрес түләмәве аркасында, җылыту өчен әнә шул сумманы яңадан исәпләгәннәр. Төп башына утыртмасыннар дисәгез, күпкатлы йортлардагы күршеләргә дә күз-колак булырга киңәш итә белгечләр. Акчаны янга калдырам дип, фатирда җылылык торбасын ябып куярга яратучы Вәли аркасында, күрше Галинең, үзе дә сизмәстән, чыгымнары арта, ди алар. Коммуналь хезмәтләр өчен белеп түлисезме?**

Татарстан Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе Сергей Крайнов җылылык өчен исәп-хисап ясау тәртибенә ачыклык кертте. Моның өчен матбугат очрашуын махсус җыйдылар.

– Билгеле булганча, узган елның 1 декабреннән ил күләмендә, шул исәптән Татарстанда, коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр артты. Россия Хөкүмәте карары нигезендә тарифлар бер ел эчендә ике тапкыр күтәрелде. Декабрьдә республиканың күпчелек районнарында бәяләр 9 процентка артты. Шунысы да бар: бәяләр кабат 2024 елның җәендә генә артачак, – диде җитәкче.

Чүп өстенә – чүмәлә дигәндәй, кыш айларында түләү кәгазьләре болай да «тешле» башлый. Чөнки җылылык өчен түләү өстәлә, ә ул гомуми бәянең 60 процентына кадәр тәшкил итәргә мөмкин. Шуңа күрә гыйнварда декабрь өчен счет-фактура алган халык аптыраушта калды.

– Гыйнвар аенда гына да халыктан коммуналь хезмәтләр өчен түләүләргә бәйле 622 мөрәҗәгать кабул иттек, – ди Сергей Крайнов. – Барлык очракларның яртысыннан да күбрәге җылылыкка туры килә. Татарстанда яшәүчеләр акчаны дөрес исәпләделәрме икән, дип борчыла. Без моңа бәйле 80нән артык мөрәҗәгатьне тикшердек инде. 17 очракта түләү кәгазендәге саннарның дөреслеккә туры килмәве ачыкланды.

Мәсәлән, башкаладагы берничә йортта урнаштырылган исәпләгеч җайланмаларның эшендә гаеп тапканнар. Ә менә Казанның Парин урамындагы 15 нче йортта ул, гомумән дә, ике ай тирәсе ватылып торган. Тик идарәче оешма вәкилләре моңа әллә ни аптырамаган. Кулланучыларга җылылыкны норматив буенча язганнар. Гәрчә мондый очракта, алдагы айларда кулланылган җылылыкның уртача күрсәткече исәпкә алынырга тиеш, дип аңлаттылар журналистларга «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында.

– Җылылык өчен акчаны артык түләүчеләргә киләсе айларда яңадан исәп-хисап ясалачак. Гыйнвар өчен кулланучыларга 525 мең сум акча кире кайтарылачак, – диде Татарстан Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе урынбасары Светлана Заһидуллина.

Җылылык өчен исәп-хисап ясаганда башны бутаган тагын бер нәрсә бар. Ул да булса, намуссыз күршеләр.

– Бу – җылылык энергиясен исәпләүче шәхси җайланмалар урнаштырылган күпфатирлы йортларда яшәүчеләргә кагыла. Сүз, нигездә, соңгы елларда төзелгән яңа йортлар турында бара. Милек хуҗалары фатир сатып ала да, анда яшәмәгәч, акчаны янга калдырам дип, торбаларны ябып куялар. Тик гамәлдәге канун буенча болай эшләргә ярамый. Җылылык өчен акча ике төр күрсәткечтән чыгып исәпләнә. Ягъни без торакны җылыткан өчен генә түгел, ә җылылык энергиясе күпфатирлы йортка кадәр килеп җиткән өчен дә түлибез. Торбаны ябып куючылар гаебе белән, фатирга кадәр кермәгән җылылык гомуми кирәк-яраклар өчен тотылган энергия буларак исәпкә алына. Күпфатирлы йортта җылылык өчен түләү берничек тә нульгә тиң була алмый, чөнки җылылык йортка кадәр килгән бит инде, – ди Сергей Крайнов.

Милек хуҗаларының коммуналь хезмәтләр өчен дөрес түләмәве аркасында 9 миллион сумлык җылылыкны яңадан исәпләгәннәр әнә.

Бу хакта сөйләгәндә, Сергей Крайнов булган бер хәлне дә искә төшерде. Моннан дистә ел элек күпкатлы йортта яшәүче берәү: «Миңа гомуми җылыту системасы кирәкми, үземә шәхсән исәпләгечләр куйдырам», – дип (элек закон моны рөхсәт иткән, хәзер юк. – **Ред.**), торбаларны яптырган. Тик берни дә эшләмәгән. Кыш көне фатирда һава температурасы 14–16 градус тәшкил иткән. Салкынча, аның каравы акча түлисе юк. Бу кешенең эзенә тиз төшкәннәр.

– Фатирлар арасындагы диварлар җылылыкны үткәрә. Шуңа күрә күршеләр торбаларны «кыскан» саен, башкалар күбрәк җылылык тотарга мәҗбүр, – дип аңлатты белгеч.

Бүген Казанда, Чаллыда һәм Түбән Камада җылылык энергиясен исәпләүче шәхси җайланмалар урнаштырылган 460 күпфатирлы йорт бар икән. Күршеләр, игътибарлырак булыгыз!

Эльвира ВӘЛИЕВА



vk.com

**Кайтаваз**

**РӘШИТ ФӘТХРАХМАНОВКА РӘХМӘТ**

Дөреслекне ачыкларга аптыраган бу заманда «ВТ»да кыю, олпат журналист Рәшит Фәтхрахмановның дөньяда, Россиядәге вакыйгаларга аерым тукталып, анализ ясап, иң мөһим сорауларга үз фикере белән шәрехләп язуы газета укучыларыбыз тарафыннан көтеп алына дип беләм. Аның мәнә шушы үзенчә аерым стильдәге язмалары өчен генә дә «Ватаным Татарстан» газетасына аерым язылып, өстәлебездә тотарлык. Әле яңадан ул «Фикер» астындагы күләмле күзәтүләрендә дөньякүләм икътисад, сәясәт, сәнәгать өлкәсендәге тормыш агышына да алып кереп, киң вә аңлаешлы мәгълүмат бирә. Икенче төрле әйткәндә, аны укысаң, берничә басманы актарып та тормыйсың – һәммәсенә иркен, аңлаешлы җавап аласың.

Әле яңарак кына хөрмәтлебез Рәшит Фәтхрахмановның 60 яшьлек юбилее уңаеннан аның хакында «ВТ»дагы кызыклы язмалардан укыдык. Үзем дә, ветеран журналист буларак, соң булса да, уң булсын дигәндәй, талантлы, тынгысыз, ихлас каләм иясен гомер бәйрәме белән тәбрикләп, аеруча «ВТ» укучыларын, гадәттәгечә, даими мәшһүр язмаларын, иманлы-көчле публицистикасын күрсәтеп-балкытып торырга язсын аңа!

Әсгать СӘГЫТДИНОВ, 1984 елдан СССР Журналистлар берлеге әгъзасы